**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Калморза торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 6 2025 елның 24 ноябре.

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45, 69 маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Калморза торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Калморза торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Калморза торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Новая урамында юлны ремонтлау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү өчен түләү);

2) Калморза торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (юл кырыен һәм аның тирәсендәге территорияне чабу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Иске Матвеевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Башлык: Д.Ш.Латыйпов